## “Тукай – мәңге күңелләрдә” бәйрәм-кичәсе

22 не апрель көнне, пәнҗешәмбе, лицеебызда Габдулла Тукай туган көненә һәм Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган әдәби – музыкаль кичә булып узды. Бәйрәмне Г.Тукай шигыренә язылган “Бәйрәм бүген” дигән җыр белән ачып җибәрделәр. Аннары сүзне лицеебыз директоры  Гөлнара Гаппасовна Галеева алды. Беренче сыйныфтан алып җиденче сыйныфка кадәр яшьтәге укучылар яраткан шагыйребез Габдулла Тукайның шигырьләрен сөйләделәр, аның әсәрләре буенча инсценировка курсәттеләр. Фольклор ансамбле «Заман» үзләренең матур күлмәкләрен киеп җырларын башкардылар. Кичәбезгә чакырылган кунаклар да булды. Алар: балалар һәм яшүсмерләр өчен чыгарыла торган “Ялкын” журналының баш мөхәррире Илназ Фаис улы Фазуллин, Яков Емельянова исемендәге мәдәният үзәгенең  иҗат жанрлары буенча белгеч Марина Петровна Тараканова, Татарстан Республикасы сәнгать эшлеклесе, GOLDEN TIME TALENT - LONDON International Festival Халыкара конкурсы җиңүчесе, "Россиянең алтын тавышы" конкурслары лауреаты, “Татар моңы” фестиваленең лауреаты Лариса Басырова, Совет районының муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф һәм мәгариф идарәсенең урынбасары Гүзәлия Гыйләҗ кызы Ибатуллина. Чакырылган кунаклар белән танышып үткәннән соң, аларның һәрберсенә сүз бирелде. Безнең укучыларыбызны бәйрәм белән котлап уңышлар теләделәр. Гомумән, кичәбез барлык тамашачыга да ошады, дип уйлап каласы килә. Беренче такыр сәхнәгә аяк баскан башкаручылар да үзләрен кыю тоттылар, чыгышларына сокланып карап утырдылар. Алдагы елларда да укучыларга сәхнә түрләрендә чыгыш ясарга насыйп булсын, үзләренең сәләтләрен башкаларга да күрсәтерлек дәрәҗәдә булсын. Барысына да уңышлар телибез!


Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халкыңның
Габдулла
Тукай
135









